Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Пестречинского муниципального района
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль
районы башкарма комитеты
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«15» февраль 2019 ел № 274

Питрәч муниципаль районының бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 21 декабрь, 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы турында 1995 елның 5 ноябрендәге 1113 номерлы карары, Россия Федерациясе Президентының «Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү турында» 2001 елның 9 ноябрендәге Указы, Россия Федерациясе субъектларында гражданнар оборонасы эшләре буенча, табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2002 елның 10 сентябрендәге 428 номерлы приказы белән расланган Россия Федерациясе субъектларында Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтләрен үстерү Концепциясе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы карарына нигезләнеп һәм гамәлдәге дежур-диспетчерлык хезмәтләренең гамәлләрен координацияләү, гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга һәм аларның даими әзерлекләрен юкка чыгаруга җәлеп ителгән көчләрнең оперативлыгын арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте турындагы нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин